РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АТНИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ

422750, село Большая Атня, улица Ш.Марджани, дом 6

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘТНӘ
РАЙОН СОВЕТЫ

422750, Олы Әтнә авылы, Ш.Мәржани урамы, 6 нчы йорт

Тел.: 8(84369)21004, факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

РЕШЕНИЕ
«25» апрель 2025 ел.

КАРАР
№275

“Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы җирле үзидарә органнарының депутатлары, сайланган вазыйфаи затлары һәм муниципаль хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турында Нигезләмәне раслау хакында” 2022 елның 29 мартындагы 120 номерлы Әтнә район Советы карарына үзгәрешләр кертү турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” 02.03.2007 ел №25-ФЗ Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында” 28.03.2018 ел № 182 карары нигезендә (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 24.04.2018 №281, 14.06.2018 №481, 17.10.2018 №940, 29.12.2018 №1320, 17.11.2021 №1087, 13.12.2021 №12222, 17.09.2022 №1015, 30.04.2024 №290, 25.09.2024 №829, 14.04.2025 №228 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) Татарстан Республикасы Әтнә район Советы карар кылды:

1. Әтнә район Советының 2022 елның 29 мартында 120 номерлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы җирле үзидарә органнарының депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына һәм муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмә”гә (Әтнә район Советының 18.11.2022 №144, 27.01.2023 №167, 15.05.2024 №228, 16.11.2024 №245 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1нче пункта «13 990» саннарын «15 389» саннары белән алмаштырырга;

1.2. Нигезләмәнең II бүлеген түбәндәге эчтәлекле яңа редакциядә бәян итәргә:

«II. Әтнә муниципаль районы башлыгы, Әтнә муниципаль районы башлыгы урынбасары, авыл җирлекләре башлыклары, авыл җирлекләре башлыклары урынбасарлары, депутатлар, Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланулы органнары эгъзалары, Әтнә муниципаль районы Контроль-хисап палатасы Рәисенең акчалата бүләкләнүе

1. Әтнә муниципаль районы башлыгы, Әтнә муниципаль районы башлыгы урынбасары, авыл җирлекләре башлыклары, авыл җирлекләре башлыклары урынбасарлары, депутатлар, Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланулы органнары әгъзалары, Әтнә муниципаль районы Контроль-хисап палатасы Рәисенең акчалата хезмәт хакы әлеге карарга 2 нче һәм 3 нче кушымталарда күрсәтелгән күләмнәрдә билгеләнә.

2. Район муниципаль берәмлекләре башлыкларына, район муниципаль берәмлекләре башлыклары урынбасарларына, үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы депутатларга, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларына, районның Контроль-хисап палатасы Рәисенә еллык түләүле отпуск биргәндә бер тапкыр түләнә торган түләү айлык акчалата түләүдән артмаган күләмдә түләнә.

3. Әтнә муниципаль районы башлыгына еллык түләүле отпуск бирелгәндә айлык акчалата бүләкләүдән һәм бер мәртәбә түләүдән тыш, өстәмә рәвештә айлык акчалата бүләкләү, эш нәтиҗәләре буенча премияләр түләнергә, шулай ук муниципаль хокукый актлар нигезендә башка түләүләр башкарылырга мөмкин.

Шул ук вакытта Әтнә муниципаль районы башлыгына айлык акчалата түләүләрнең гомуми күләме Татарстан Республикасы министрына айлык акчалата түләүләрнең гомуми күләменнән 0,9 дан артмаска тиеш.

4. Әтнә муниципаль районы башлыгы урынбасарына айлык акчалата бүләкләүдән һәм еллык түләүле отпуск биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләүдән тыш, өстәмә рәвештә айлык акчалата бүләкләү, эш нәтиҗәләре буенча премияләр түләнергә, шулай ук муниципаль хокукый актлар нигезендә башка түләүләр башкарылырга мөмкин. Шул ук вакытта Әтнә муниципаль районы башлыгы урынбасарына айлык акчалата түләүләрнең гомуми күләме Әтнә муниципаль районы башлыгына айлык акчалата түләүләрнең гомуми күләменнән 0,55 тән артмаска тиеш.

5. Муниципаль районның авыл җирлекләре башлыкларына һәм авыл җирлекләре башлыклары урынбасарларына айлык акчалата бүләкләүдән һәм еллык түләүле отпуск биргәндә бер мәртәбә түләүдән тыш, муниципаль хокукый актлар нигезендә өстәмә рәвештә айлык акчалата бүләкләү, тиешле еллар эшләгән өчен айлык өстәмә түләү, премияләр түләнергә мөмкин..

6. Әтнә муниципаль районының Контроль-хисап палатасы Рәисенә, айлык акчалата бүләкләүдән һәм еллык түләүле отпуск биргәндә бер мәртәбә түләүдән тыш, өстәмә рәвештә айлык акчалата бүләкләү, эш нәтиҗәләре буенча премияләр түләнергә, шулай ук муниципаль хокукый актлар нигезендә башка түләүләр башкарылырга мөмкин. Шул ук вакытта аларның акчалата түләүләренең айлык җыелма күләме Әтнә муниципаль районы Башлыгына акчалата түләүләрнең айлык җыелма күләменнән 0,55 тән артмаска тиеш.

7. Әтнә муниципаль районының авыл җирлекләре башлыкларына һәм авыл җирлекләре башлыклары урынбасарларына айлык акчалата бүләкләү түләнгәндә, күрсәтелгән затларның хезмәт өчен түләү чыгымнары күләме айлык акчалата бүләкләүне түләү өлешендә хезмәт өчен түләүнең 11 төркеменә кертелгән авыл җирлекләре башлыклары өчен елына 16,85 айлык акчалата бүләкләү хезмәт өчен түләүнең 12 төркеменә кертелгән авыл җирлекләре башлыклары - елына 15,48 айлык акчалата бүләкләү, аларның хезмәт өчен түләүнең унберенче төркеменә кертелгән урынбасарлары өчен - елына 17,27 айлык акчалата бүләкләү, хезмәт өчен

түләүнең 12 төркеменә каралган - елына 15,38 айлык акчалата бүләкләү нормативыннан артмаска тиеш.»

1.3. Нигезләмәнең III өлешендәге 4 пунктыннын 4.6. подпунктында «41 процент» сүзләрен «58 процент» сүзләренә алмаштырырга;

1.4. Нигезләмәнең IV өлешендәге 1 пунктыннын 6 нчы подпунктында «41 процент» сүзләрен «58 процент» сүзләренә алмаштырырга;

1.5. күрсәтелгән карарга 2 нче һәм 3 нче кушымталарны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

2. Әлеге карар 2025 елның 01 маеннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы һәм Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында http://atnya.tatarstan.ru. адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисенә йөкләргә.

Әтнә муниципаль районы
башлыгы урынбасары
Әтнә район Советы
рәис урынбасары Ф.М. Нуриев

2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Советы 29.03.2022 елгы 120 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Әтнә район Советы «25» апрель 2025 №275 карары редакциясендә)

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы җирле үзидарә башлыкларын, депутатларын, сайланулы вазыйфаи затларын, нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә даими ашыручы, Контроль-хисап палатасы Рәисе, айлык акчалата бүләкләү күләмнәре

Вазыйфаларның исемнәре	Коэффициент
	8 нче группа
1	2
Муниципаль берәмлек башлыгы	40740
Муниципаль берәмлек башлыгы урынбасары	36667
Контроль-хисап органы рәисе	36667

3 нче кушымта
Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Советы 29.03.2022 елгы 120 номерына (Татарстан Республикасы Әтнә район Советы «25» апрель 2025 № 275 карары редакциясендә)

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы җирле үзидарә башлыкларын, депутатларын, сайланулы вазыйфаи затларын, нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә даими ашыручы, Контроль-хисап палатасы Рәисе, айлык акчалата бүләкләү күләмнәре

Вазыйфаларның исемнәре	Айлык акчалата бүләкләү күләме, сум	
	Унберенче группа	Уникенче группа
Муниципаль берәмлек башлыгы	23091	21091
Муниципаль берәмлек башлыгы урынбасары	16594	15391
Депутат	15389	15389
Җирле үзидарәнең сайлап куелган органы әгъзасы	15389	15389